| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

№ 192-р 30 март 2015 ел

Урман утырту көнендә чараларны оештыру турында

Урманга сак караш тәрбияләү, урман ресурсларын саклау, яңадан торгызу һәм арттыру проблемаларына җәмгыять игътибарын җәлеп итү, шулай ук Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан урманнарда санитар-экологик хәлнең уңай торышы тәэмин итү максатында:

1. 1. «Нурлат урманчылыгы» ДБУ, «Нурлатлес»ДБУ тәкъдим итәргә:

- Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Икеайлык үткәрү турында» 2015 елның 17 апрелендәге 161-р номерлы боерыгы белән игълан ителгән «Урман утырту көне»традицион республика табигатьне саклау акциясе чараларын 2015 елның 25 апрелендә һәм 3 октябрендә оештырырга;

- тиешле эшләр башланганчы хезмәт куркынычсызлыгы буенча максатчан инструктажны мәҗбүри үткәрүне тәэмин итү.

2. Җирле үзидарә органнарына, авыл җирлекләре башлыкларына, иҗтимагый оешмаларга, милекнең барлык рәвешләрендәге оешмалар һәм учреждениеләр җитәкчеләренә урман үсентеләрен дәүләт урман фонды җирләре составындагы урман кишәрлекләренә салуда катнашырга тәкъдим итәргә.

3. «Татмедиа» ААҖ филиалларына «Дуслык» («Дружба», «Туслах») газетасы һәм «Нурлат» телерадиокомпаниясе редакцияләренә әлеге чараларны уздыруны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны, урманга сак караш турында материаллар бастыруны һәм чыгаруны тәкъдим итәргә.

4. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары һәм Нурлат шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесенә (килештерү буенча)йөкләргә.

ТР Нурлат муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Ә.К. Габдуллин